


# ЧИШМӘ БАШЫ

**МБМБУ "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"**

**№3 гыйнвар 2025**



15 нче гыйнвар көнне безнең балалар бакчасында Наласа авылында яшәп иҗат итүче ,Казанда "Мәгариф-Вакыт" нәшриятендә Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, балалар шагыйрәсе Гөлчирә Мәхмүт кызы Нәҗметдинова иҗатына багышланган “Кар өстендә кызыл алма” дигән очрашу кичәсе уздырылды. Һәр төркем балалары сәнгатьле итеп шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар, биеделәр. Шагыйрә белән очрашу күңелгә ятышлы истә калырлык булды, балалар шат күңел белән таралыштылар.



22 нче гыйнварда Арча шәһәренең үзәк китапханәсендә Наласа авылында яшәп иҗат итүче шагыйрә, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, балалар өчен язылган ”Ак тәлинкә, сары май”, ”Кәнфит тавы”, ”Кар өстендә кызыл алма” китаплары авторы Гөлчирә Мәхмүт кызы Нәҗметдинова белән бик күркәм,кызыклы очрашу булды!Безнең балаларыбыз шагыйрәнең шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләп,җырларын тыңлап,табышмакларга җаваплар табып, куанып,зур канәгатьлек хисе белән кайттылар.Бу матур очрашуны оештыручыларга чиксез рәхмәтебезне белдерәбез



26 нчы гыйнвар конне районыбыздан махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм колоннасы җибәрелде.

Гуманитар ярдәмне җыюда өлеш керткән һәркемгә олы рәхмәтебезне белдерәбез. Күңел җылысы биреп әзерләнгән ярдәм, хәер-догалар ир-егетләребезгә исән-имин, тиз арада туган якларына әйләнеп кайтырга насыйп итсен!










28 нче гыйнварда Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» һәм “ Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте” белән берлектә "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"нда “Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән нейроуеннар һәм күнегүләр куллану буенча "Төрле уеннар мөһим, төрле уеннар кирәк» темасына республикакүләм семинар булып узды. Чарада Арча, Саба, Балтач һәм Кукмара районы балалар бакчалары өлкән тәрбиячеләре, тәрбиячеләр һәм белгечләр катнашты. Семинар кунакларын бакча мөдире Лиана Сөләйманова сәламләде. Башка балалар бакчаларыннан килгән тәрбиячеләр “Балачак”тагы хезмәттәшләре чыгышын карап һәм тыңлап кына калмады, үзләренең эш тәҗирбәсе белән дә уртаклашты.

Семинарга нәтиҗәне Арча педагогия көллияте укытучысы Сәрия Шәмсетдинова һәм мәгариф бүлеге методисты Алинә Иманаева ясады. Хезмәттәшләребезнең эш тәҗрибәләре, осталыклары семинар кунакларында зур соклану уятты.



## Ә сез кыш турында ниләр беләсез?

Шулай итеп, сезгә - кыш турында кызыклы фактлар.

1. Кар бөртекләре, кешеләр кебек үк, бер-берсеннән аерылалар. Еллар буе барган тикшеренүләрдә бер-берсенә охшаш ике кар бөртеге табылмаган.

2. Боз сөңгеләре күп очракта йортның көньяк өлешендә барлыкка киләләр.

3. Җир йөзендәге 7 миллиардтан артык кешенең яртысыннан артыгы бер тапкыр да кар күрмәгән.

4. Кеше кулына эләккән иң эре кар бөртегенең диаметры 38 см булган.

5. Иң салкын температура 2013 елда җир йөзенең иң салкын материгында – Антарктидада теркәлгән. Тикшеренүчеләр минус 91,2 градус күрсәткечен эләктереп кала алганнар.

6. Антарктида материгында иң биек тауда кызыл, сары һәм алсу төстәге карны күргәннәр.

7. Кар бөртекләре суга әйләнергә өлгермәгән пардан ясалалар, 90 процент һавадан торалар, шуңа күрә җилсез көнне җиргә бик акрын төшәләр.

8. Иң салкын киңлекләрдә даими торган нык салкыннар вакытында кар бик катыга әйләнә һәм аңа суккач, яңгыравык металл тавышына охшаган аваз чыга.

9. Кайбер кешеләр кышны яратмыйлар гына түгел, аннан куркалар да. Алар салкыннан, кардан, боздан куркалар. Психологлар бу күренешне “кионофобия” дип атыйлар. Мондый авыру вакытында бер генә юл – яшәргә ел әйләнәсе җылы булган көньяк илләргә күченү.



10. Кар үзенә төшкән кояш нурларын кире кайтара. Шуңа күрә ул кояшлы көндә нык кына сукырайта һәм шунлыктан кыш көне җир җылынмый. Кояш нурларының 90 проценты диярлек кире космоска китә.

11. Чиста кар ашау өчен яраклы. Ләкин, аны ашаганда, организмыгызны калорий белән баетуга караганда, энергияне күбрәк тотасыз.

12. Кар бөртекләре җырларга сәләтле. Тик, ишетү сәләте чикләнгәнлектән, кеше бик түбән ешлыкларны ишетми. Галимнәр туңган кристалларның суга кагылгач аваз чыгарганнарын ишеткәннәр. Сүз уңаеннан, бу аваз балыкларны бик ярсыта.

13. Бозның туңу варианты – берничә. Иң салкыны булып Антарктика бозы исәпләнә, аның салкынлыгы -60 градуска җитә. Гренландия бозлыкларында бу күрсәткеч – минус 28 градус. Ә иң юка, уалучан боз 0 градуста була һәм аны Европа Альплары түбәсендә очратырга мөмкин.

## *1 нче урын бездә!*





ДИПЛОМ

НАГРАЖДАЕТСЯ

МБДОУ «Арский детский сад №7»

(директор Суляйманова Лиана Ильясовна)

I место

за новогоднее оформление подведомственной территории в конкурсе «Новогодняя феерия»

Глава Арского муниципального района И.Г. Нуриев

Арск, 2024-2025


## *Искечә Яңа ел!*

Яңа елны бәйрәм иттек. Ләкин, гадәт буенча, аны 13 гыйнвардан 14енә каршы иске стиль буенча да билгеләргә күнегеп беттек. Үз тарихында ел исәбен алыштырган һәр илдә искечә Яңа ел – рәсми булмаган күңелле бәйрәмнәрнең берсе. Аны бәйрәм итү каян килеп чыккан соң?

Русиядә бу яңа гадәт революциядән соң формалаша. Сәбәбе – Юлиан календареннан Григорианныкына күчү. Ике календарь арасында аерма 13 көн тәшкил итә. Димәк, рәсми рәвештә Яңа елны каршылаганнан соң иске стиль белән бәйрәм итү арасы да 13 көн.

Яңа календарь белән яши башлау, бәлки, ел башлану датасын үзгәрткән дә булыр иде. Тик моңа урыс православие чиркәве әһелләре каршы төшә.

Ун-унбиш еллап элек искечә Яңа елны бәйрәм итүгә артык әһәмият бирелми иде. Хәзер ул елдан-ел популярлаша бара. Календарьда кызыл төс белән билгеләнмәсә дә, халык мәш килеп көтә бу көнне. Телевидение исә Яңа ел программаларын һәм традицион фильмнарны кабатлап күрсәтә. Бу – ике атна элек күрми калучылар өчен менә дигән мөмкинлек.




### Сез кечкенә мажарага әзерме?

Әйдәгез, гади кәгазьне кызыклы жирафка әйләндерик! Оригами – ул вак моториканы, игътибарлылыкны үстерү, балаларның иҗади потенциалын ачу мөмкинлеге.

17 гыйнварда бөтен дөньяда «Балалар уйлап табулары көне» билгеләп үтелә. Әлеге көн балаларга фантазиягә ирек бирү өчен бик яхшы сәбәп. Гади тылсым килеп чыкканын сабыйларга күрсәтегез һәм аларның куллары шедеврлар ясасын!

Әзерләделәр: Аглиуллина А.Р., Сайфуллина Л.Р.



Тиен

Мин - тиен, тиен, тиен!
Мин- матур, житез тиен!
Сыйланырга килегез,
Чикләвек тулы өем...

Г. Корбанова





## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

«Ананаслы салат»

Салатны ясау өчен:

- тавык түше ите
- йомырка
- каты сыр
- консервланган ананас
- әстерхан чикләвеге
- майонез.

Тавык итен пешергәч саламлап турарга яки алдан турап, тәмләткечләр кушып, табада кыздырып алырга.

Ингредиентларны язылган тәртиптә салырга һәм һәр катына майонез салырга, иң өске катта чикләвек булачак.




Тутырылган татлы борыч – күпләр яратып ашый торган шактый популяр ризыкларның берсе.

Ингредиентлар: татлы борыч, 600-700 грамм фарш, 1,5 стакан дөге, 2-3 суган, 4-5 помидор, томат согы, кайнаган су, борыч, тоз, яшеллек (укроп, петрушка).

Борычларны юарга, орлыкларын алырга. Әчлек әзерләү өчен ингредиентларны барысын бергә болгатырга һәм борыч эченә тутырырга, кәстрүльгә тезәргә. Борычларны капларлык итеп, су кушылган томат согы салырга.

Табынга каймак яки майонез белән бирергә мөмкин.

Әзерләде: Баһаветдинова Л.Ш.



## ӘЙДӘГЕЗ УЙНЫЙБЫЗ!

«Кыш килде»

Бу уенда катнашучылар алып баручыны сайлыйлар, ә аннары аннан башка барысы да махсус килешенгән урын буенча — мәсәлән, ишегалды өлеше буйлап-йөгерәләр һәм теләсә нинди ышык урыннар артына: агач, багана артына, балалар мәйданчыгына һәм башка урыннарга качалар. Алып баручы әйтә: "Бүген җылы, кояш балкый, барыгыз, йөрегез!" ди - һәм уенчылар ышык урыннардан мәйданчыкка йөгереп чыга. Алып баручы «Кыш килде! Тизрәк өйгә кайтыгыз!", диюгә уенның башка катнашучылары тагын ышык урыннарга йөгерәләр. Ә алып баручы аларны качып өлгергәнче тотарга тырыша.

"Төньяк җил, көньяк җил»

Бу уен өчен катнашучылар ике йөртүче сайлыйлар. Берсе төньяк, икенчесе көньяк җилгә әйләнә. Калган уенчылар мәйдан буйлап йөгерәләр. Төньяк җиле катнашучыларны тота һәм катнашучылар туктасын өчен аларны» катыра". Ә көньяк җиле, аларга кулы белән кагылып, «ирекле» дип кычкырып, «эретә».




### Кроссворд «КЫШ»











**Горизонталь:**

**3.** Без кайда уйныйбыз?

**4.** Кыш көне нәрсә ява?

**6.** Кыш көне урамда нинди һава?

**8.** Кыш көне төннәр нинди?

**Вертикаль:**

**1.** Нәрсә белән шугалакта шуалар?

**2.** Кыш көне каты җил чыккач, нәрсә була?

**5.** Кыш көне нәрсә белән шуалар?

**7.** Хәзер кайсы ел фасылы?

Әзерләде Галиева А.И.

## Беренче сыйныф укучыларының ата-аналары өчен киңәшләр:

Тиздән сезнең балагыз мәктәп бусагасын атлап керәчәк, бу аның бөтен гадәти тормышын сизелерлек үзгәртәчәк. Балалар бакчасыннан мәктәпкә күчү-һәр бала тормышында мөһим баскыч. Яңа социаль шартларга эләккәндә, балалар еш кына аларга әзер булмый, бу аларның эмоциональ өлкәсенә тәэсир итә. Шуңа күрә баланы мәктәпкә әзерләү мөһим, сез хәзер өйрәткән бар нәрсә дә аңа мәктәптә уңышлы булырга ярдәм итәчәк.

1 нче киңәш. Мәктәп, укыту шартлары һәм укытучы белән алдан ук танышыгыз.

2 нче киңәш. Бала белән ул мәктәптә очраша торган кагыйдәләр һәм нормалар турында фикер алышыгыз. Аларның кирәклеген һәм максатка ярашлылыгын аңлатыгыз.

3 нче киңәш. Балага өйдә шөгыльләнү өчен урын бүлеп бирегез.

4 нче киңәш. Балада аның мәктәп укучысы булырга омтылышын хуплагыз.

5 нче киңәш. Балага карата артык таләпләрдән сакланыгыз.

6 нчы киңәш. Булачак беренче сыйныф укучысы белән бергә көн тәртибен төзегез һәм аның үтәлешен күзәтегез.

7 нче киңәш. Баланы үз әйберләрен һәм мәктәп кирәк-яракларын тәртиптә тотарга өйрәтегез. 8 нче киңәш. Баланың хата ясарга хокукы бар. Шуңа күрә аның беренче уңышсызлыкларына бөтен өметләрегезнең җимерелүенә караган кебек Карамагыз. Исегездә тотыгыз: аңа сезнең ярдәмегез һәм ярдәмегез бик кирәк.

9 нчы киңәш. Укудагы беренче кыенлыкларны калдырмагыз. Теләсә нинди кыенлыкларга игътибар итегез, бигрәк тә алар еш була башласа.

10 нчы киңәш. Балагызны уку белән артык мәшгуль итмәгез. Беренче сыйныф укучысының уеннар өчен җитәрлек вакыты калырга тиеш.